РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОЗЮРИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Школьная 1А село Старые Зюри , 422091
тел.: (884360) 52-6-25 (факс)
E-mail: Szur.Tul @tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ҖӨРИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Мәктәп урамы, 1А, Иске Җөри авылы,422091
тел.: (884360) 52-6-25 (факс)
**E-mail: Szur.Tul @tatar.ru**

ОКПО 94318056 ОГРН 1061675010429 ИНН/КПП 1619004404/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№1** **«1» февраль 2021 ел.**

Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге Башкарма комитетының 11.12.2015 ел 14нче номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2021 елның 15 гыйнварындагы 11/13-09/111 номерлы, 2021 елның 22 гыйнварындагы 11/13-09/236 номерлы хатларын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге Башкарма комитетының 11.12.2015 ел 14нче номерлы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына (06.05.2020елның 11 номерлы, 28.10.2020елның 19 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1)** Агач һәм куаклар кисүгә, кронировкалауга яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты:

А) 2.6 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә::

«Салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле йөкләмәләрнең булуы яки булмавы турында белешмә (авария хәлләренә бәйле эшләрне башкару очрагында бирелми).».

2.9 пунктының икенче абзацын түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча белән тулыландырырга:

«5) Салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле йөкләмәләрнең булуы (авария хәлләренә бәйле эшләрне башкару очрагында бирелми).».

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Иске Җөри авыл җирлеге
Башкарма комитеты
җитәкчесе

Р.Р.Мараков